**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. № 15 «03» май 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советының 2023 елның 29 декабрьнең 61 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселокның бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселок бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 25.12.2023 № 628-ФЗ Федераль закон нигезендә,

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советының 2023 елның 29 декабрьнең 61 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселокның бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Актүбә шәһәр тибындагы поселок бюджет процессы турындагы нигезләмәгә 6 статьясының 5 өлешен түбәндәге эчтәлектәге 12.1 пунктчасы белән тулыландырып үзгәрешне кертергә:

«12.1) иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмати системасында «Электрон бюджет» капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат формалаштыра, аларга капиталь кертемнәрне финанс белән тәэмин итү (финанслау) чыганагы булып федераль бюджет акчалары тора (капиталь төзелеш объектларыннан һәм дәүләт оборона заказына кертелгән күчемсез милек объектларыннан тыш);».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Азнакай районы Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советының бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис А.Л. Севостьянов